ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.04.2020 № 240

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 2 апрелендәге 191 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясе Торак кодексына күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны җайга салучы нормаларны тәртипкә салу өлешендә үзгәрешләр кертү турында" 27.12.2018 ел, № 558-ФЗ Федераль законга, "Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" 29.05.2009 ел, № 116-ФЗ Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. "Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) торак урын дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 15 маендагы 528 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында", Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын, 2013 елга кадәр авылны социаль үстерү" федераль максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында торак шартларын яхшырту өчен исәпкә кую һәм гражданнар, шул исәптән социаль түләүләрне файдаланып, торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән яшь белгечләр исемлекләрен формалаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын, Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне башка категориягә күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын, Торак биналарны торак булмаган биналарга, торак булмаган биналарны - торакка күчергәндә документларны рәсмиләштерүнең Административ регламенты"н раслау турында 02.04.2020 елның 191 номерлы Башкарма комитет карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бинаны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) торак урын дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында", Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль

хезмәт күрсәтүнең административ регламентын, 2013 елга кадәр авылны социаль үстерү" федераль максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында торак шартларын яхшырту өчен исәпкә кую һәм гражданнар, шул исәптән социаль түләүләрне файдаланып, торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән яшь белгечләр исемлекләрен формалаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын, Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне башка категориягә күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын, Торак биналарны торак булмаган биналарга, торак булмаган биналарны - торакка күчергәндә документларны рәсмиләштерүнең Административ регламенты"н раслау турында Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2012 елның 15 маендагы 528 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:”

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов